«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы

мәгариф һәм фән министры

_________ И.Г.Һадиуллин

«23» ноябрь 2020 нче ел

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең**
**рус телле укучылары өчен 2021 нче елда**
**туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру**
**материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант**
**контрольных измерительных материалов для проведения в 2021 году**
**государственной итоговой аттестации (ГИА)**
**по родному (татарскому) языку**
**для русскоязычных учащихся школ с русским языком обучения**

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## Имтихан эшенең күрсәтмә вариантына аңлатма

2021 нче елгы күрсәтмә вариант белән танышканда, шуны күз алдында тотарга кирәк: әлеге варианттагы биремнәр 2021 нче елда үтәчәк имтихан эшенең барлык эчтәлек вариантларын да чагылдырмый.

2021 нче елда үтәчәк имтиханда тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге төп дәүләт имтиханын үткәрү өчен укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр һәм эчтәлек элементлары кодификаторында китерелә.

Күрсәтмә вариант имтиханда катнашучы һәркемгә һәм киң җәмәгатьчелеккә булачак имтихан эшенең төзелеше һәм биремнәр саны, шулай ук аларның катлаулылык дәрәҗәсе турында күзаллау булдыру мөмкинлеге бирүгә юнәлтелгән.

16

# Рус телендә белем бирү мәктәпләренең рус телле укучылары өчен 2021 нчы елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Татар теленнән төп дәүләт имтиханын тапшыру өчен, 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә. Имтихан эше **33 биремне** үз эченә алган **4** бүлектән тора. **1 нче бүлектәге** 13 бирем (1 – 13 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. **2 нче бүлектәге** 7 бирем (14 – 20 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә. **3 нче бүлектәге** 8 бирем (21 – 28 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала. **4 нче бүлектәге** 29 – 32 нче биремнәр җөмлә калыпларын үзгәртеп язуны күздә тота. Ачык типтагы 33 нче бирем укучыларның язма сөйләмен тикшерүгә юнәлдерелгән.

**Уңышлар телибез!**

## Инструкция по выполнению работы

Время, отведенное на выполнение заданий – 3 часа 55 минут (235 минут). Экзаменационная работа по татарскому языку состоит из четырех разделов, включающих 33 задания. **Раздел 1** (задания по аудированию) включает 13 заданий на понимание аутентичных текстов (задания 1 - 13). **Раздел 2** (задания по чтению) включает в себя 7 заданий (задания 14 - 20). **Раздел 3** (задания по лексике и грамматике) состоит из 8 заданий (задания 21 - 28). **Раздел 4** (задания по письменной речи) состоит из 4 заданий на трансформацию предложений (задания 29 – 32) и задания, в котором предлагается написать личное письмо (задание 33).

**Желаем успеха!**

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Ял көнне Гүзәл кая барырга тели?**

1) әбисенең юбилеена

2) туган көн бәйрәменә

3) бүләкләр кибетенә

**2** **Дуслар кичен нишләргә телиләр?**

1) ярышта катнашырга

2) бию түгәрәгенә барырга

3) һавада йөрергә

**3** **Гүзәл кем белән киного барган?**

1) апасы

2) энесе

3) әтисе

**4** **Кышын Гүзәлнең абыйсы нишләргә ярата?**

1) өстәл уеннары уйнарга

2) шугалакка йөрергә

3) тау чаңгысында шуарга

**5** **Гүзәл кем булырга тели?**

1) тарихчы

2) биюче

3) җырчы

**6** **Гүзәл буш вакытында кемнәр белән аралашырга ярата?**

1) сыйныфташлары

2) күршеләре

3) апасы

**7** **Мәктәптә кемнәр белән очрашу булачак?**

1) әдәбиятчылар

2) галимнәр

3) телчеләр

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Җәен Алсу бакчада эшләргә яратмый.

1) текстка туры килә   2) текстка туры килми

**9** Азатка футбол уйнау ошый.

1) текстка туры килә   2) текстка туры килми

**10** Азатның энесе абыйсы белән лото уйнарга ярата.

1) текстка туры килә   2) текстка туры килми

**11** Алсуга җәйге урман бик ошый.

1) текстка туры килә   2) текстка туры килми

**12** Азатның гаиләсе чит илләргә сәяхәт итәргә ярата.

1) текстка туры килә   2) текстка туры килми

**13** Августта Азат гаиләсе белән әнисенең апасында ял итә.

1) текстка туры килә   2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

Сәнгать белән кызыксынучыларның игътибарына!
19 нчы гыйнварда танылган татар рәссамы Зөфәр Гыймаевның "Хәзинә" милли сәнгать галереясендә күргәзмәсе ачыла. Экспозициядә рәссамның 80 гә якын хезмәте белән таныша аласыз. Алар арасында тематик картиналар да, табигать күренешләре дә, портретлар да урын алган. З.Гыймаев – татар халкының күренекле кешеләренең образларын иҗат иткән рәссам.
Көтеп калабыз!

**Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**

1) "Хәзинә" галереясендә үткәреләчәк рәссам белән очрашу турында.
2) Татарстанның Милли музеенда ачылачак яшь рәссамнар күргәзмәсе турында.
3) Милли сәнгать галереясендә эшли башлаячак күргәзмә турында.

**15**

Кадерле укучылар!
21 нче февраль – Халыкара туган тел көне. Ул 2000 нче елдан башлап билгеләп үтелә. Бу көнне мәктәптә зур бәйрәм булачак. Хәзер һәр сыйныфта әзерлек эшләре бара. Укучылар туган тел турында шигырьләр өйрәнәләр, стена газеталары чыгаралар, викториналарда катнашалар, татар телчеләре турында чыгышлар әзерлиләр.
21 нче февраль көнне сезне мәктәпнең актлар залында көтеп калабыз! Килегез!
Бәйрәм 15 сәгатьтә башлана.

**Бу хәбәр нәрсә турында?**

1) Мәктәптә үткәреләчәк татар телчеләре белән очрашу турында.
2) Мәктәп укучылары өчен оештырылачак тел бәйрәме турында.
3) Мәктәптә үткәрелгән Туган тел бәйрәме турында.

**16**

Сәлам, Гөлназ! Хәлләрең ничек? Әти-әниең исән-саулармы? Кайсы фәннәрдән имтиханнар бирәчәксең?
Минем хәлләрем бик яхшы. Әти-әнием, апам да исән-саулар. Хәзер мин имтиханнарга әзерләнәм. Рус теле белән математикадан тыш, мин инглиз теле һәм биологиядән имтихан бирергә булдым. Күп укырга, тестлар эшләргә кирәк. Җәйге каникулда синең белән "Сәләт" лагеренда күрешербез дип ышанам. Бу очрашуны бик көтәм. Бик сагындым сине, дустым! Имтиханнарыңны уңышлы тапшыр. Җәйгә кадәр! Дустың Рузилә

**Электрон хат аша Рузилә дустына нәрсә турында язган?**

1) Җәйге каникулда дусты белән очраша алмавы турында.
2) Инглиз теле белән химиядән бирәчәк имтиханнары турында.
3) Дустын сагынуы һәм аның белән очрашырга теләве турында.

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Шулай да бу уку дигәннәре... Таш кисәр идек, укымас идек! Икенче чирек тә үтеп бара. Иң авыры – рус теле, дибез. Юк, алай түгел, иң авыры – психология. Меланхолик, сангвиник, холерик, флегматик, имеш. Гыйззәтуллин – меланхолик, Әлтафи - флегматик, Зарифуллин – холерик, имеш. Юк, иң авыры – немец теле. Беренчедән, ул үзе - дошманның теле. Укытучысы нечкә аяклы, ябык яңаклы, нәзек озын бармаклы бер кеше.

- Син ничә тел беләсең, шуның кадәр әйбәтрәк кеше буласың, дип йөрәкне боза.

- Син бүген бер "ике" ле алдың, димәк, син, Гитлер тегерменәнә бер чүмеч су салдың. Син бер "биш" ле алдың, димәк, син фашизмга удар ясадың.

Һәр сүзе – ярага тоз. Җитмәсә, татар сүзләрен дә үзенчә бозып сөйләп үзәккә үтә. "Бүген" дими – "бөген", "соңга калдың" дими – "сыңа калдың"...

- Немец теле – бөек тел! Немец милләте дөньяга Гетены, Шиллерны, Бетховенны бирде. Немец халкы кешелек җәмгыятенә Марксны, Энгельсны, Либкнехтны бирде.

Миләр кабара, баш шаулый...

- Немец телен Владимир Ильич бик яхшы белгән, Фридрих Энгельс сигездән артык тел белгән...

Моннан соң ничек яшәрбез, бер генә чит тел белмибез бит! Шуны уйлагач, баш мие бөтенләй эшләүдән туктый. Ә сары күлмәкле укытучы сөйләвен дәвам итә:

- Без бүгенге көндә сезнең белән немец милләтенә каршы көрәшмибез. Без сезнең белән фашистларга каршы көрәшәбез. Немец булу әле ул фашист булу дигән сүз түгел.

– Бүген без узган дәрестә өйрәнгән "Колаямбу" текстын кабатлыйбыз. Тагын газап башлана. Әйе, әйе, бу текст хәтердә. Һәр сүзен хор белән әйттерде. "Нох айн маль, нох айн маль…" Янәсе, тагын бер мәртәбә, тагын бер мәртәбә.

Менә монда бер сүз бар, диде. Анысы французча. "Плантаге" дип язылган. "Плантэжэ" дип укырга, диде, берничә тапкыр әйтеп күрсәтте. Ул көнне Әлтафи хәтта авылына хат та язды. Имеш, немец телен без инде су урынына эчәбез, ну, шуның өстенә аз-маз француз телен дә өйрәнгәлибез... (*М.Мәһдиевтан*)

**17** Немец теле укытучысы телләр белү турында нинди фикер әйткән?

1) Иң авыры – немец теле.

2) Кеше күпме тел белсә, шуның кадәр яхшырак була.

3) Телләр белү – зур байлык ул.

18 Укытучы фикеренчә, немец теле ни өчен бөек тел?

1) Бу телне бөтен кешеләр дә белә.

2) Бу телне белүчеләр аз.

3) Бу тел күп танылган кешеләрнең туган теле булган.

19 Укучылар дәрестә нишлиләр?

1) Өйрәнгәнне искә төшерәләр.

2) Текстны тәрҗемә итәләр.

3) Үткән дәрестә өйрәнгәнне язалар.

20 Әлтафи хатында нәрсә турында язган?

1) Ул немец, француз сүзләрен язган.

2) Ул яңа сүзләрне берничә тапкыр язган.

3) Ул телләр өйрәнү турында язган.

**Раздел 3**

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

**Сабан туе**

Сабан туе — элек-электән татар халкының яраткан бәйрәме. Сабан туе — язгы эшләрне (21) ... бәйрәме. Ул, гадәттә, июнь башында үткәрелә, шимбә көнне — авылларда, ә якшәмбе көнне район үзәкләрендә була. 25 нче июньнән (22) ... Казанда үтә.

Сабан туе Идел буенда (23) ... барлык милләтләрнең дә уртак бәйрәменә әйләнде. Анда татар халкы белән бергә рус, мари, удмурт, башкорт һәм башка халыклар да катнаша. Бәйрәмне үткәрү (24) ..., тигез һәм уңайлы урын сайлана. Бу урын мәйдан дип атала. Авыл халкы һәм кунаклар, (25) ... бәйрәмчә киенеп, җәяү яки машина белән килә.

Сабан туенда иң зур ярыш — көрәш. Татар (26) ... сөлге тотып көрәшәләр. Һәр көрәшче көндәшенең биленнән сөлге белән урап тота һәм аны җиргә егарга тырыша. Көрәшне малайлар (27) ... җибәрәләр. Аннары мәйданда, чиратлашып, яшүсмерләр, егетләр, урта яшьләрдәге ирләр көрәшә. Көндәшен аркасына яткырган кеше җиңә. Көрәштә батыр (28) ... тәкә һәм кыйммәтле бүләк бирәләр.

| 21 | 1) тәмамларга | 2) тәмамлау | 3) тәмамлый |
|---|---|---|---|
| 22 | 1) кадәр | 2) бирле | 3) соң |
| 23 | 1) яшәгән | 2) яшиләр | 3) яшәргә |
| 24 | 1) турында | 2) өчен | 3) белән |
| 25 | 1) мәйданнан | 2) мәйданны | 3) мәйданга |
| 26 | 1) көрәшендә | 2) көрәштә | 3) көрәшен |
| 27 | 1) башларга | 2) башлыйлар | 3) башлап |
| 28 | 1) калырга | 2) калучыга | 3) кала |

## Раздел 4

***Прочитайте задания 29 - 32. Допишите второе предложение так, чтобы оно по значению совпадало с первым. Используйте не больше трех слов в каждом предложении. В бланк ответов перепишите только пропущенные слова, без интервала как в примере.***

ҮРНӘК | **0** Кичә, авыру сәбәпле, мин укуга бара алмадым.

**Кичә мин мәктәпкә бармадым, чөнки ...**

| 0 | **АВЫРДЫМ** |
|---|---|

**29** Җәйге ял җиткәч, мин дусларым белән очрашырмын.

**Җәй ... белән, дусларым белән күрешермен.**

30 Дустымны инглиз теленнән район олимпиадасында җиңүе белән ихлас күңелдән котладым.

**Дустым инглиз теле буенча район олимпиадасында..., шунлыктан мин аны ихластан тәбрикләдем.**

31 Чит телләрне яхшы белергә теләсәң, шул телләрдә аралашырга тырыш.

**Чит телләрне яхшы ... өчен, шул телләрдә аралашу бик файдалы.**

32 Өй эшен әзерләгәч, мин саф һавада йөрим.

**Башта мин өй эшен ..., аннары саф һавага чыгам.**

33 **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**

**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Мәктәптә миңа күп фәннәр ошый, ләкин мин аеруча тарих белән кызыксынам. Мин Интернеттан кызыклы мәгълүматлар укыйм, олимпиадаларда катнашам, призлы урыннар алам.*

*... Сиңа кайсы фән күбрәк ошый?... Бу фән сиңа ни өчен ошый? ... Бу фәнне яхшырак белү өчен, син нәрсәләр эшлисең?*

**ҖАВАПЛАР**

| Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | 3 |
| 5 | 1 |
| 6 | 3 |
| 7 | 2 |

| | |
|---|---|
| 8 | 2 |
| 9 | 1 |
| 10 | 1 |
| 11 | 1 |
| 12 | 2 |
| 13 | 2 |
| 14 | 3 |
| 15 | 2 |
| 16 | 3 |
| 17 | 2 |
| 18 | 3 |
| 19 | 1 |
| 20 | 3 |
| 21 | 2 |
| 22 | 3 |
| 23 | 1 |
| 24 | 2 |
| 25 | 3 |
| 26 | 1 |
| 27 | 3 |
| 28 | 2 |
| 29 | ҖИТҮ/КИЛҮ |

| | |
|---|---|
| 30 | ҖИҢДЕ/ҖИҢГӘН/ҖИҢҮ ЯУЛАДЫ<br>ҖИҢҮ ЯУЛАГАН |
| 31 | БЕЛҮ |
| 32 | ӘЗЕРЛИМ/ЭШЛИМ |

**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**

**Беренче сорау. Ял көнне Гүзәл кая барырга тели?**

**Гүзәл**: Сәлам, Рүзәл! Хәлләр ничек?

**Рүзәл**: Сәлам, Гүзәл! Әйбәт, рәхмәт. Үзең нихәл?

**Гүзәл**: Рәхмәт, ярыйсы. Эшләрем бик күп. Бүген дәресләрдән соң бүләк алырга барасым бар, ә кичен биологиядән контроль эшкә әзерләнергә кирәк. Ял көнне дус кызымның туган көне, ул кунакка чакырды. Ә синең планнарың нинди ял көннәренә, Рүзәл?

**Рүзәл**: Минем дә эшләр күп әле. Бүген мәктәптә волейбол буенча район ярышы була, анда мин дә катнашырга тиеш. Ял көннәрендә гаиләбез белән авылга кайтабыз, чөнки әбиемнең юбилеен бәйрәм итәбез. Аңа җитмеш яшь тула. Бөтен балалары, оныклары җыела.

**Гүзәл**: Ә бүген волейбол ярышы ничәдә башлана? Минем дә бик карыйсым килә.

**Рүзәл:** Алтынчы дәрестән соң дип әйтте физкультура укытучысы. Ярышта алты команда катнашачак.

**Гүзәл**: Яхшы, Рүзәл, әйтүең өчен рәхмәт сиңа. Мин килергә тырышырмын, сыйныфташларыма да әйтермен. Бергә күңелле булыр.

**Рүзәл**: Рәхмәт сиңа, Гүзәл! Килегез. Җанатарлар күп булганда, уйнарга җиңелрәк.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Дуслар кичен нишләргә телиләр?**

**Гүзәл**: Рүзәл, сәлам! Син мәктәпкәме?

**Рүзәл**: Сәлам, Гүзәл! Әйе, мәктәпкә. Бүген сәгать өчтә шахмат буенча мәктәп беренчелеге була. Безнең сыйныфтан мин катнашам. Ә син кая барасың? Син дә мәктәпкәме, бию түгәрәгенәме?

**Гүзәл:** Юк. Миңа даруханәгә барырга кирәк. Әнием авырый. Температурасы югары, тамагы да авырта. Мин мәктәптә булганда, табиб килгән, дарулар язган. Хәзер шуларны сатып алырга кирәк. Бүген биюгә бара алмыйм инде.
**Рүзәл:** Ярар алайса, тоткарламыйм. Сиңа ашыгырга кирәк. Әниең тизрәк терелсен, миннән сәлам әйт.
**Гүзәл:** Рәхмәт, Рүзәл, яхшы сүзләрең өчен. Ярыштан кайткач, миңа шалтырат. Кичен урамда очрашырбыз һәм саф һавада йөрербез. Дәресләр әзерләгәнче, ял итәргә, саф һава суларга кирәк бит. Син ризамы?
**Рүзәл:** Әлбәттә, риза. Кайту белән хәбәр бирермен, Гүзәл. Хәерле юл сиңа!
**Гүзәл:** Рәхмәт, сиңа да уңышлар, Рүзәл. Барысын да җиңәргә тырыш!
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Гүзәл кем белән киногa барган?**
**Рүзәл:** Сәлам, Гүзәл, ял көнне нишләдең? Өйдә булдыңмы?
**Гүзәл:** Көндез өйдә булдым, ә кичен кинога бардым. Кинотеатрларда яңа фильм башланган. Бик кызык диде апам. Шуңа күрә мин дә энем белән барырга булдым.
**Рүзәл:** Нинди фильм? Мин ишетмәдем әле. Исеме ничек дисең?
**Гүзәл:** Фильмның исеме - "Соник". Ул фэнтези жанрында. Безгә бик ошады. Аның төп герое – зәп-зәңгәр төстәге керпе.
**Рүзәл:** Алай икән. Ник миңа да әйтмәдегез? Минем дә карыйсым килә. Кайсы кинотеатрда бара?
**Гүзәл:** Алмаз Синема Гранд кинотеатрында. Безне әти илтте машина белән. Бик тиз җыенырга туры килде. Вакыт аз иде.
**Рүзәл:** Аңлашылды. Ярар, мин дә карармын әле.
**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Кышын Гүзәлнең абыйсы нишләргә ярата?**
**Рүзәл:** Сәлам, Гүзәл! Бүген тагын шугалакка барасыңмы?
**Гүзәл:** Юк, Рүзәл, гафу ит, бүген бара алмыйм. Бүген өй эшем күп, инглиз теленнән тестка әзерләнергә кирәк. Иртәгә тест тапшырабыз. Чирек бетәргә бер атна гына калды бит. Яхшы билге алырга кирәк.
**Рүзәл:** Алайса иртәгә барыйк. Иртәгә дәресләрдән соң буш буласыңмы?
**Гүзәл:** Иртәгә дә барып булмый әле, Рүзәл. Иртәгә абыем белән чаңгыда шуарга барырга сөйләштек. Аны дуслары чакырган. Ул мине дә алып барырга сүз бирде. Кыш җиткәч, алар шулай атна саен берничә дус тау чаңгысында шуарга баралар. Абыем спортчы бит. Ул дзюдо белән дә шөгыльләнә, шахмат та уйный.

**Рүзәл:** Кызык. Минем дә өйрәнәсем килә. Куркыныч түгелме? Абыең яхшы шуамы инде? Ә син? Син өйрәнәсең генәме әле?
**Гүзәл:** Әйе. Минем беренче баруым гына әле. Абыем ярдәм итәрмен диде. Курыксам да, шуып карыйсым килә. Телевизордан күрсәтәләр бит, бик күп кызлар бу спорт төрен ярата. Икенче тапкыр барганда, сине дә үзебез белән алырга абыемнан рөхсәт сорармын.
**Рүзәл:** Ярар. Рәхмәт сиңа, дустым. Уңышлар телим. Күңелле ял итегез. Абыеңа да миннән сәлам әйт. Иртәгә очрашкач, барысын да сөйләрсең.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Рүзәл кем булырга тели?**
**Гүзәл:** Рүзәл, бер сорау бирергә ярыймы сиңа?
**Рүзәл:** Әйе, тыңлыйм. Сора. Сине нәрсә кызыксындыра, дустым?
**Гүзәл:** Тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, син укуыңны мәктәптә дәвам итәргә җыенасыңмы?
**Рүзәл:** Башта мин 10 нчы сыйныфка барырмын дип уйлаган идем, ләкин хәзер башкачарак уйлыйм. Минем белән бергә шахмат түгәрәгенә йөрүче дустым Казандагы Мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумына укырга керергә җыена. Мине дә шунда чакыра. Шуңа күрә тугызынчы сыйныфтан соң китәрмендер.
**Гүзәл:** Кызык икән хәлләр! Мин әле бергә мәктәпне тәмамларбыз да университетка укырга керербез дип хыялланып йөри идем. Синең планнар башкачарак икән, дустым. Минем өчен бу ачыш. Шулай да мин синең өчен шат, чөнки кем булырга теләвеңне хәзер үк яхшы аңлыйсың. Кирәкле һөнәр сайлагансың. Хәзер бит Интернет заманы. Мондый белгечләр кирәк.
**Рүзәл:** Ә син, мәктәпне тәмамлагач, кем булырга телисең, Гүзәл? Биючеме? Син бик матур биисең бит. Әти-әниең дә - танылган артистлар.
**Гүзәл:** Юк шул! Биюгә мин үзем өчен генә йөрим. Ә һөнәр сайлау – бик җаваплы эш дип саныйм. Әйдә, әйтеп кара әле, мин кем булырга телим икән?
**Рүзәл:** Тәрҗемәчеме? Хисапчымы? Укытучымы?
**Гүзәл:** Бер җавабың да дөрес түгел, дустым. Тарихчы буласым килә минем. Менә шулай. Белеп тор.
**Рүзәл:** Бик яхшы һөнәр сайлагансың, котлыйм, Гүзәл!
**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Гүзәл буш вакытында кемнәр белән аралашырга ярата?**
**Гүзәл:** Сәлам, Рүзәл, якшәмбе көнне нишләргә җыенасың?

**Рүзәл:** Төгәл генә белмим әле. Техникумда Ачык ишекләр көне дип әйткәннәр иде. Дустым белән шунда барырбыз дип планлаштырам. Анда сәгать унда булырга кирәк. Ә син кая барырга җыенасың?
**Гүзәл:** Ял көнне безне күршеләр чәй эчәргә чакырды, аларның кызлары кияүгә чыкты. Шуңа күрә бәйрәм чәенә чакырдылар. Көндез әнием белән аларга керәсебез бар.
**Рүзәл:** Ә-ә-ә, алай икән. Бергәләп чәй эчү күңелле инде ул. Ә кичен? Кичләрен синең кемнәр белән аралашасың, сөйләшәсең килә?
**Гүзәл:** Гадәттә, мин сыйныфташларым белән урамда йөрергә яки кафега барырга яратам. Анда без бөтен яңалыклар турында сөйләшәбез. Ә шулай да буш вакытымны апам белән үткәрү күбрәк ошый, чөнки ул мине борчыган бөтен сорауларга җавап бирә, кызыклы мисаллар китерә. Ул шундый күп белә!
**Рүзәл:** Шундый җан дустың булу бик яхшы, Гүзәл.
**Гүзәл:** Рәхмәт, Рүзәл. Син хаклы.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Мәктәптә кемнәр белән очрашу булачак?**
**Гүзәл:** Рүзәл, сәлам, 21 нче февральдә мәктәптә нинди бәйрәм үткәрелә, беләсеңме?
**Рүзәл:** Минемчә, бу көн – Халыкара туган тел көне. Димәк, Туган телгә багышланган бәйрәм үтәчәк. Хәтерлисеңме, былтыр бу көнне кызыклы викторина үткәргәннәр иде.
**Гүзәл:** Ә-ә-ә, исемә төште. Без дә катнаштык бит. Тугызынчы В сыйныфы командасы җиңү яулаган иде. Быел бу бәйрәм атнаның кайсы көненә туры килә? Җомгагамы?
**Рүзәл:** Әйдә, календарьдән карыйк әле. Юк, шимбәгә. Егерме беренче февраль шимбә була. Сыйныф җитәкчесе әйткән иде бит үткән атнада, быел мәктәптә кызыклы очрашу булачак дип.
**Гүзәл:** Шулаймыни? Кемнәрне чакыралар бу очрашуга? Танылган татар әдәбиятчыларынмы?
**Рүзәл:** Аларны гына түгел, тел өлкәсендә эшләүче берничә галимне чакырабыз дип әйтте укытучы. Алар безнең алда чыгыш ясаячак, укучыларның сорауларына җавап бирәчәк.
**Гүзәл:** Аңлашылды, Рүзәл! Алайса безгә телләр турында кызыклы сораулар әзерләргә кирәк булачак.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных***

*утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.*

**[пауза 20 секунд]**

**Азат**: Сәлам, Алсу!

**Алсу**: Сәлам, Азат!

**Азат**: Алсу, син җәйге ялны ничек үткәрәсең?

**Алсу:** Башта июнь аенда мин шәһәрдә булам. Әнием белән бакчага йөрим. Без анда яшелчәләр, матур-матур чәчәкләр утыртабыз. Бакчабыздан ерак түгел кечкенә күл бар. Яшьтәшләрем белән шунда су коенырга йөрибез, балык тотабыз. Кичләрен бадминтон, волейбол уйныйбыз. Ә син җәйге каникулда нәрсәләр эшлисең, Азат?

**Азат**: Гадәттә, миңа ялның беренче аен шәһәрдә үткәрергә туры килә. Ял вакыты булгач, еш кына без дусларыбыз белән стадионга футбол уйнарга йөрибез, елгада су керәбез, кояшта кызынабыз, паркларда күбрәк булырга тырышабыз. Гаиләбез белән туганнарыбызга кунакка барырга да яратам. Анда рәхәтләнеп аралашабыз, барлык яңалыклар турында сөйләшәбез, күңел ачабыз.

**Алсу:** Вакыт күп булгач, кинога да еш йөрисеңдер әле, шулаймы, Азат?

**Азат:** Әйе, кызык фильмнар булганда, энем белән кинога йөрибез, кызык мульфильмнар да карыйбыз. Ә инде кичләрен без энем белән өстәл уеннарын уйныйбыз, пазллар җыябыз. Вакыт та күңелле үтә, игътибарлыкны да арттыра мондый уеннар.

**Алсу:** Кызык! Өстәл уеннары мине дә кызыксындыра. Хәзер алар яшьләр арасында бик популяр бит. Син дә аларны яратасың икән. Вакытың булганда, энең белән безгә килегез, бергәләп уйнарбыз, кеше күбрәк булса, тагын да кызыграк бит.

**Азат:** Яхшы, сөйләштек. Каникулның башка айларында кайларда буласың, Алсу? Июль, августны да Казанда үткәрәсеңме?

**Алсу:** Юк, июль аенда мин авылда әбием белән бабамда ял итәм. Аларның авылы искиткеч матур урында урнашкан. Авылдан ерак түгел зур урман бар. Анда күрше кызлары белән җиләк, гөмбә җыярга йөрибез. Җәен урманда шундый рәхәт! Кошлар сайрый, хуш исле чәчәкләр үсә. Урманның һавасы чиста. Шулкадәр яратам мин җәйге урманны! Ә инде август аенда гаиләбез белән диңгезгә ял итәргә барабыз. Гадәттә, анда ике атна булабыз. Кайткач, мәктәпкә әзерләнә башлыйм.

**Азат:** Минем дә әти-әнием, гадәттә, июль аенда ял алалар, һәм без гаиләбез кая да булса сәяхәт итәргә яратабыз. Бер җәйне, мәсәлән, Алтайда булдык, икенче елны Карелиягә, Валаам утравына бардык. Сәяхәт безгә бик тә ошады. Августта әниемнең сеңлесенә авылга кайтабыз. Анда бер атна ял итеп киләбез.

**Алсу:** Менә ничек үтә ялларыбыз, Азат. Быел да җәйге ял күңелле үтсен!

**Азат:** Рәхмәт, Алсу! Шулай булсын!

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**У вас есть 6 минут, чтобы внести ответы в специальный бланк.**

**Шәхси хат язу биремен бәяләү критерийлары**

*1 нче таблица*

| К | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| К1 | Коммуникатив бурычны үтәү | ***Эш тулысынча башкарылган:*** 3 сорауга да тулы җавап бирелгән. Мөрәҗәгать итү, саубуллашу һәм имзалау фразалары дөрес сайланган. Алынган хатка рәхмәт белдерелгән | ***Эш башкарылган:*** 3 сорауга да җавап бирелгән, әмма берсенә бирелгән җавап тулы түгел. Хат стилен бозган 1-2 төгәлсезлек бар ***һәм/яки*** алынган хатка рәхмәт белдерелмәгән | ***Эш өлешчә башкарылган***: 2 сорауга гомуми җавап бирелгән, әмма 1 сорауга бирелгән җавап тулы түгел ***яки*** бер сорауга гомумән җавап юк. Хат стилен бозган 3 яки күбрәк төгәлсезлек бар, итагатьлелек формалары сакланмаган | ***Эш башкарылмаган:*** 2 сорауга җавап бирелмәгән ***яки*** текстның күләме тулмый |
| К2 | Текстны оештыру | | Текст логик эзлеклелектә төзелгән һәм абзацларга бүленештә хаталар юк; тел чаралары дөрес кулланылган; хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килә | Текст, гомумән алганда, логик эзлеклелектә төзелгән, ләкин логик бәйләнешләрдә ***һәм /яки*** абзацларга бүленештә ***яки*** хатның төзелешендә 1-2 төгәлсезлек бар | Текст төзелешендә логик эзлеклелек сакланмаган; язма текст төзелешендә 3 яки күбрәк хата бар, ***яки*** хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килми. |
| К3 | Текстның | Коммуникатив | Текстны аңлауга | Текстны аңлауга | Текстны аңлауга |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | лексик-грамматик төзелеше | бурычны үтәү өчен кирәк булган төрле лексик һәм грамматик чаралар файдаланылган (текстны аңлауга зыян китермәгән 1-2 төгәлсезлек рөхсәт ителә) | зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (3-4 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***яки*** тел хаталары юк, ләкин артык гади лексик һәм грамматик чаралар кулланылган | зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (5-6 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***һәм /яки*** текстны аңлауга зыян китерә торган 1-2 грамматик хата бар | зыян китерә торган хаталар 6 дан күбрәк |
| К4 | Орфография һәм пунктуация | | Орфографик һәм пунктуацион хаталар юк, **яки** текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 1-2 хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 3-4 орфографик һәм пунктуацион хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерә торган орфографик һәм пунктуацион хаталар 4 тән күбрәк |

Шәхси хат язу биреме К1-К4 критерийлары буенча тикшерелә. Максималь **10 балл** алырга мөмкин.

Текстның эчтәлеге биремгә туры килмәсә (язма хат характерында булмаса, **тәкъдим ителгән сорауларга җавап урынына башка мәгълүмат язылса**, тәкъдим ителгән хат күчереп кенә язылса) бу бирем өчен 0 балл куела.

Хатның күләме **30** сүздән ким булса, К3 һәм К4 критерийлары буенча максималь балл куелмый.

Эшнең күләмен билгеләгәндә, беренче сүздән алып соңгысына кадәр (шулай ук адрес, язылу вакыты, имза да) исәпкә алына. **Хатта укучы үзенең чын исемен, адресын күрсәткән очракта эш тикшерелми.**

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0 - 12 балл – «2» ле билгесе;

13 - 20 балл – «3» ле билгесе;

21 - 31 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен (1-13 нче биремнәр) баллары 7 дән кимрәк булмаска тиеш. Әгәр укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 7 дән кимрәк булса, «3» ле билгесе куела.

32 - 42 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 10 нан кимрәк булмаска тиеш. Әгәр укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 10 нан кимрәк булса, «4» ле билгесе куела.